СОВЕТ
НОВОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 3, с.Новый Кырлай,
Арский муниципальный район, 422035

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урам, 3 йорт, Яңа Кырлай авылы,
Арча муниципаль районы, 422035

Тел. (84366)56-7-32, факс (84366)56-7-34. E-mail: Nkrl.Ars@tatar.ru

**Арча муниципаль районы**
**Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**« 17 » февраль 2021ел** **№ 15**

**Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җиренә кермәгән һәм физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләргә кермәгән Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге территориясендәге яшел үсентеләрне кисү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында**

Россия Федерациясе Урман кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законы, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Уставы нигезендә, Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә кермәгән һәм физик һәм юридик затлар милкендәге җирләргә кермәгән Яңа Кырлай авыл җирлеге территориясендәге яшел үсентеләрне рациональ файдалану, саклау һәм яңадан торгызу максатларында, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә кермәгән һәм физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләргә кермәгән Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге территориясендәге яшел үсентеләрне кисү тәртибе турында Нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлеге бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Яңа Кырлай авыл
җирлеге башлыгы Г.Г.Сәфәров

СОВЕТ НОВОКЫРЛАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН1609012702

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы
карарына кушымта

**Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә кермәгән һәм физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләргә кермәгән Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге территориясендәге яшел үсентеләрне кисү тәртибе турында**

**НИГЕЗЛӘМӘ**

Әлеге Нигезләмә Россия Федерациясе Конституциясе, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Граждан кодексының 15 ст., Россия Федерациясе Урман кодексының 61, 68, 77 ст., Яңа Кырлай авыл җирлеге Уставы нигезендә, халыкның экологик иминлеген тәэмин итү максатларында эшләнде һәм Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә кермәгән һәм физик затлар милкендәге җирләргә кермәгән Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге территориясендәге яшел үсентеләрне кисү тәртибен билгели.

**1. Төп төшенчәләр**

Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

Яшел үсентеләр - табигый һәм ясалма үсеп чыккан агач, куак һәм үләнчел үсемлекләр (паркларны, скверларны, бакчаларны, газоннарны, чәчәклекләрне, шулай ук аерым үсүче агач һәм куакларны да кертеп).

Табигать территорияләре - бердәм географик (климат) шартларында формалашкан җирлек, туфрак, үсемлекләр рельефының билгеле бер типларын үз эченә алган, хуҗалык эшчәнлегенә кагылмаган яисә аз кагылган территорияләр.

Яшел территорияләр - табигый үсеп чыккан үсемлекләр кишәрлекләре булган территорияләр, ясалма рәвештә яшелләндерү объектлары (авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән тыш), төрле функциональ билгеләнештәге җирләрнең аз төзелгән өлешләре, алар чикләрендә өслекнең 50 процентыннан да ким булмаган өлеше үсемлекләр капламы белән каплана.

Урманланган территорияләр - табигый үсеп чыккан урман үсемлекләре белән капланган төрле функциональ билгеләнештәге табигать территорияләре.

Агач -яңа утыртылган үсентеләрдән тыш, диаметры ачык беленеп торган кимендә 5 см кәүсәле, 1,3 м биеклектәге үсемлек.

Куаклык - туфрак өслегендә тармакланган күпьеллык (агачтан аермалы буларак) үсемлек.

Үлән капламы - газон, табигый үлән үсемлекләре.

Ешлыклар - нинди дә булса урында куе булып үскән үсемлекләр, куаклар.

Яшел массив - бердәм үскән 50 данәдән дә ким булмаган зур агачлар (15 яшьтән өлкәнрәкләр) үсә торган территория.

Яшел үсентеләрне зарарлау - яшел үсентеләрнең я туфракның зарарлы матдәләр белән пычрануы, ут төртү яисә башка йогынты ясау нәтиҗәсендәаларның үсеше тукталу, шул исәптән ботакларның, тамыр системасының механик зарарлануы, кабыкның бөтенлеге бозылу, туфракның тере катламы бозылу.

Яшел үсентеләрне юкка чыгару (юк итү) - яшел үсентеләрне кисү яки аларның үсешен туктатуга китергән башка төрле зарарлаулар.

Компенсацион яшелләндерү - юкка чыгарылган яисә зарарланган яшел үсентеләр урынына 2 коэффиценты белән яңа үсентеләр утырту.

## 2. Яшел үсентеләрне саклауның төп принциплары

Авыл җирлеге территориясендә үсә торган яшел үсентеләр саклагыч, рекреацион, эстетик функцияләр башкара һәм сакланырга тиеш.

2.1. Авыл җирлеге территориясендә (авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән тыш) үскән барлык яшел үсентеләр (агачлар, куаклар) сакланырга тиеш.

2.2. Авыл җирлеге территориясендә яшел үсентеләрне саклауны тәэмин итү бурычлары түбәндәгеләргә йөкләнә:

2.2.1. Оешмаларга үзләре белдергән эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру өчен бирелгән кишәрлекләрдә - әлеге оешмалар җитәкчеләренә;

2.2.2. Милектәге яисә арендадагы җирләрдә - юридик затларга һәм гражданнарга - милекчеләргә яисә арендалаучыларга.

2.3. Яшел үсентеләр үскән җир кишәрлекләренең милекчеләре, файдаланучылар һәм арендалаучылар яшел үсентеләрнең сакланышын, тиешенчә карауны тәэмин итәргә тиеш.

2.4. Әлеге Нигезләмә авыл җирлеге территориясендә проектлау, төзелеш, ремонтлау һәм башка эшләр алып барганда агач-куак үсентеләрен кисүгә бәйле эшләр башкарган барлык гражданнарга һәм оешмаларга, милек рәвешләренә бәйсез рәвештә кагыла.

2.5. Авыл җирлеге территориясендә хуҗалык, шәһәр төзелеше һәм башка эшчәнлек Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы һәм әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән яшел үсентеләрне саклау таләпләрен үтәп гамәлгә ашырыла.

2.6. Җир кишәрлегендә төзелеш, хуҗалык һәм башка эшчәнлек башкарганда, проект алды һәм проект документациясендә яшел үсентеләрнең торышы турында тулы һәм дөрес белешмәләр һәм проектлана торган объектның яшел үсентеләргә йогынтысын тулысынча бәяләгән акт булырга тиеш.

2.7. Яшел үсентеләрнең тереклек эшчәнлеген тәэмин итә алмый торган яшелләндерелгән территорияләрне һәм яшел массивларны куллану рөхсәт ителми.

## 3. Яшел үсентеләрне (агачларны, куакларны) кисү тәртибе

3.1. Авыл җирлеге территориясендә яшел үсентеләрне рөхсәтсез кисү тыела.

3.2. Авыл җирлеге территориясендә агачларны һәм куакларны кисү рөхсәт нигезендә башкарыла. Кисүгә рөхсәт авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе күрсәтмәсе рәвешендә рәсмиләштерелә.

3.3. Яшел үсентеләрне кисүгә рөхсәт алу өчен мөрәҗәгать итүче авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе исеменә билгеләнгән рәвештә (1 нче кушымта) хат-заявка бирә, анда үсентенең саны, исеме, аларның торышы, чикләнгән кисү үткәрелү урыны һәм аны нигезләү күрсәтелгән булырга тиеш. Гаризага түбәндәге документлар теркәп бирелә:

3.3.1. Шәхесне таныклый торган документлар;

3.3.2. Вәкаләтле вәкилнең вәкаләтләрен раслый торган документ (әгәр мөрәҗәгать итүче исеменнән вәкил эш итсә);

3.3.3. Якындагы корылмаларга яисә башка ориентирларга кадәр киселергә тиешле яшел үсентеләр төшерелгән кишәрлек схемасы;

3.3.4. Җир кишәрлеге Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрында теркәлмәгән булса, җир кишәрлегенә хокук билгели торган һәм җир кишәрлегенә хокукны раслаучы документларның таныкланган күчермәләре;

3.3.5. Биналар һәм корылмалар төзегәндә габаритларга эләгә торган яшел үсентеләрне кискән очракта, расланган проект документациясе;

3.3.6. Кагылган территорияләрнең хуҗалары белән яшел үсентеләрне кисү һәм күчереп утырту шартларын килештерү;

3.3.7. Агач утыртканда яисә күчереп утыртканда, инженер челтәрләре вәкилләре белән җир эшләрен уздыруга ордер ачып килештерү.

3.4. Авыл җирлеге башкарма комитеты, заявка-хат кергәннән соң, гариза бирүчегә әлеге эш төрен үткәрүгә рөхсәте булган махсуслаштырылган оешмага түбәндәгеләрне алу өчен мөрәҗәгать итәргә киңәш итә:

3.4.1. яшел үсентеләрнең санлы исемлеге;

3.4.2.киселергә тиешле агач үсентеләренең санын, төрен, категориясен билгеләү максатыннан, үскән яшел үсентеләрне натураль тикшерү акты;

3.4.3. киселгән агач өчен (түләү) бәясен исәпләп чыгару. Киселгән агач өчен түләү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2007 елның 22 маендагы 310 номерлы карары белән расланган ставкалар нигезендә аерым исәпләнә.

Югарыда күрсәтелгән эшләр мөрәҗәгать итүче хисабына башкарыла.

Рөхсәтнең гамәлдә булу вакыты - 90 көн.

3.5. Авыл җирлеге башкарма комитеты гариза бирүченең хат-гаризасы нигезендә яшел үсентеләрне табигый техник тикшерү акты, киселгән агач өчен бәяне (түләүне) исәпләп чыгару нигезендә, авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең авыл җирлеге территориясендә яшел үсентеләрне кисүгә рөхсәт бирү турында күрсәтмә проектын әзерли.

3.6. Эшләр башкаруга рөхсәт алганда, аның мәнфәгатьләрендә яшел үсентеләр юкка чыгарыган мөрәҗәгать итүче, әлеге Нигезләмә нигезендә яшел үсентеләрне кискән өчен түләүләр кертергә һәм компенсацион яшелләндерүнең тәртибен раслый торган документлар тапшырырга тиеш.

3.7. Агач һәм куакларны кискән өчен түләү гариза бирүче тарафыннан авыл җирлеге бюджетына күчерелә.

3.8. Яшел үсентеләрне кисү эшләре билгеләнгән нормалар һәм кагыйдәләр нигезендә гариза бирүче акчалары исәбенә башкарыла. Агачларны кисү бары тик аттестацияләнгән белгечләр тарафыннан гына рөхсәт ителә.

3.9. Яшелүсентеләрне кисү, төпләү һәм калдыкларны төяү һәм чыгару эшен мөрәҗәгать итүче хисабына эш башланганнан соң өч көн эчендә башкарыла. Киселгән яшел үсентеләрне һәм киселгән калдыкларны эш урынында саклау тыела.

3.10. Территориянең кисү урынына якын урнашкан территориядә газон, яшел үсентеләр зарарланган очракта, эшләр башкаручы, территориянең хуҗасы һәм контроль органнары белән алар компетенциясе чикләрендә килештереп, әмма зыян китерелгән вакыттан ярты елдан да соңга калмыйча, аларны мәҗбүри рәвештә торгызу эшләрен башкара.

3.11. Агач һәм куакларны бушлай кисү авыл җирлегенең башкарма комитеты тарафыннан түбәндәге очракларда рөхсәт ителергә мөмкин:

3.11.1. яшел үсентеләрне тәрбияләү, санитар кисүләр һәм реконструкцияләү буенча кисүләр үткәрү;

3.11.2 авария хәлендәге һәм башка гадәттән тыш хәлләрне бетерү, шул исәптән җир асты коммуникацияләрен һәм капиталь инженерлык корылмаларын ремонтлау;

3.11.3. дәүләт санэпидемнадзор бәяләмәсе булса, торак һәм иҗтимагый биналарда яктылыкны каплый торган агач һәм куакларны кисү;

3.11.4. авария тудыра торган (җимерелү куркынычы тудыра торган) агач һәм куакларны кисү.

3.12. Югарыда күрсәтелгән очракларда, яшел үсентеләрне кисүне гамәлгә ашыручы мөрәҗәгать итүчегә авыл җирлеге башкарма комитеты белән килештерелгән урыннарда компенсацион яшелләндерү үткәрергә кирәк.

3.13. Авария хәлендәге, коры-сары һәм куркыныч тудыручы яшел үсентеләр 2 нче кушымта нигезендәге акт буенча комиссия тикшерүе нигезендә киселә.

3.14. РФ Урман кодексының 20 статьясына тәңгәл рәвештә, хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәсендә үскән яки аны гражданга яисә юридик затка тапшырганнан соң җир кишәрлегендә табигый рәвештә үскән агач-куаклык аның милке булып тора, ул аңа ия, файдалана һәм үз милке белән җитәкчелек итә.

3.15. Яшел үсентеләрне рөхсәтсез кисү яисә юкка чыгару дип түбәндәгеләр танылa:

3.15.1. Агач һәм куакларны рөхсәтсез кисү яисә рөхсәт белән, әмма рөхсәттә күрсәтелгән урында, рөхсәттә күрсәтелгән токымнарны, рөхсәттә күрсәтелгән санда кисмәү;

3.15.2. Ут төртү яисә ут белән саксыз эш итү нәтиҗәсендә агачларны һәм куакларны юкка чыгару яки зарарлау;

3.15.3.Кәүсәне боҗралау яки юну;

3.15.4. Үсеп килгән агачһәм куакларны үсүе тукталганчы зарарлау;

3.15.5. Агачларны һәм куакларны ташландык сулар, химик матдәләр, калдыклар һәм башкалар белән зарарлау;

3.15.6 Корыган агачларны рөхсәтсез кисү;

3.15.7.Үсә торган агачларны һәм куакларны башкача зарарлау.

3.16. Дәүләт урман фондында үскән агачларны һәм куакларны кисү махсус вәкаләтле дәүләт органнары тарафыннан бирелгән рөхсәтләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.17. Әлеге Нигезләмәне бозып, агачларны һәм куакларны юк итү үзирекле кисү булып тора һәм Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә административ һәм җинаять җаваплылыгына тартыла. Әлеге Нигезләмә кагыйдәләрен үтәү авыл җирлеге территориясендә барлык гражданнар, оешмалар һәм учреждениеләр өчен мәҗбүри.

## 4. Компенсацион яшелләндерү

4.1. Компенсацион яшелләндерү рөхсәт ителгән кисүләр, яшел үсентеләрне законсыз зарарлау яки юкка чыгару очракларында гамәлгә ашырыла. Компенсацион яшелләндерү алдагы сезонда, агачлар, куаклар һәм газоннар утырту өчен яраклы вакытта, әмма яшел үсентеләрне зарарлау яки юкка чыгару факты билгеләнгән вакыттан алып бер елдан да соңга калмыйча башкарыла.

4.2. Компенсацион яшелләндерү гражданнарның яисә юридик затларның мәнфәгатьләрендә яисә аларның хокукка каршы гамәлләре нәтиҗәсендә яшел үсентеләр зарарлану яки юкка чыгу очракларында, аларның акчалары исәбенә башкарыла.

4.3. Әлеге Нигезләмә нигезендә яшел үсентеләргә китерелгән зыян натураль рәвештә - компенсацион яшелләндерүгә: юкка чыгарылган яшел үсентеләрне яңадан 2 коэффиценты белән торгызылырга тиеш.

## 5. Шәһәр төзелеше эшчәнлеген башкарганда, яшел үсентеләрне саклау

5.1. Авыл җирлегендә шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыру яшел үсентеләрне саклау таләпләрен үтәп алып барыла.

5.2. Яшел территорияләр, шул исәптән яшел массивлар, шулай ук яшелләндерелгән территорияләрне үстерү өчен билгеләнгән җирләр максатчан билгеләнешсез төзелергә һәм кулланылырга тиеш түгел.

5.3. Яшел үсентеләр утыртылган җир кишәрлекләрендә төзелеш алып барганда, проект документациясе киселергә тиешле яшел үсентеләргә бәя бирергә тиеш. Мондый очракларда киселгән агач өчен зыянны каплау әлеге Нигезләмәнең 2 һәм 3 бүлекләрендә билгеләнгән тәртиптә компенсацион яшелләндерү юлы белән гамәлгә ашырыла.

## 6. Эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашырганда, яшел үсентеләрне саклау

6.1. Авыл җирлеге башкарма комитеты рөхсәтеннән башка яшелләндерелгән территорияләрдә һәм яшел массивларда сәүдә һәм башка эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен палаткалар һәм башка корылмалар урнаштыру тыела.

6.2. Эшмәкәрлек эшчәнлеген яшелләндерелгән территорияләрдә һәм яшел массивларда гамәлгә ашырганда, шартлау, ут чыгу куркынычы тудыру һәм агулы матдәләр куллану, территорияне пычрату һәм чүпләү, яшел үсентеләргә зыян китерү яисә аларны юкка чыгару тыела.

## 7. Административ җаваплылык.

7.1. Әлеге Нигезләмәне бозуда гаепле затлар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә җаваплы.

Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә кермәгән
һәм физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге
җирләргә кермәгән Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Яңа Кырлай авыл җирлеге территориясендәге
яшел үсентеләрне кисү тәртибе турында
НИГЕЗЛӘМӘГӘ 1 нче кушымта

Арча муниципаль районы
Яңа Кырлай авыл җирлеге
башкарма комитеты
җитәкчесенә
______________________
______________________
______________________
______________________
( оешманың исемен яисә Ф.И.А.И., адресын күрсәтергә)

ГАРИЗА
Яңа Кырлай авыл җирлеге территориясендә агач-куак үсентеләрен
чикле кисүгә

_____________ җир кишәрлегендә үскән агачларны, куакларны, агач-куак үсентеләрен (кирәклесен сызарга) кисүне рөхсәт итүегезне сорыйм.

______________________________________________________________________

(оешманың исемен яисә Ф.И.А.И. җир кишәрлегенә хокукның төрен күрсәтү)

һәм җирдә урнашкан ______________________________________________

(торак пунктны күрсәтергә)

Җир кишәрлегендә бар:

агачлар ______________________________ данә

куаклыклар ___________________________ данә.

Җир кишәрлеген үзләштерү һәм төзекләндерү процессында агачны кискән өчен түләүне гамәлгә ашырырга һәм дендроплан нигезендә агач-куаклыкны компенсацияләү өчен түләргә бурычлымын.

_____________ _______________
Ф.И.А.И. (Имза)
Дата _____________

Кушымталар:

1. Рөхсәт документациясе.
2. Аңа төре һәм кисү күздә тотыла торган яшел үсентеләр санын төшереп, җир кишәрлеге планы.

Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә кермәгән
һәм физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге
җирләргә кермәгән Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Яңа Кырлай авыл җирлеге территориясендәге
яшел үсентеләрне кисү тәртибе турында
НИГЕЗЛӘМӘГӘ 2 нче кушымта

АКТ
ЯШЕЛ ҮСЕНТЕЛӘРНЕ КИСЕЛЕРГӘ ТИЕШЛЕ ДИП ТАНУ ТУРЫНДА

Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Башкарма комитеты "_____"_______________ел

Комиссия составы:

1.____________________________________________________________

( Ф. И, А.И., вазыйфа)

2.____________________________________________________________

( Ф.И. А.И., вазыйфа)

3.____________________________________________________________

( Ф. И. А.И., вазыйфа)

яшел үсентеләрне тикшерде.

Тикшерү нәтиҗәләре түбәндәгечә:

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

__________________________________________________

Нәтиҗәләр:

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________

Комиссия әгъзалары:

________________________ _______________________

(имза) (Ф.И. А.И. )

________________________ _______________________

(имза) (Ф.И. А.И.)

_________________________ _________________________

(имза) (Ф.И. А.И.)